**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2023 Исәнбай авылы № 30-2

Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының 22.01.2018 елның 36-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны башлангыч юридик тикшерү һәм Федераль Законнар мониторингы нәтиҗәләре буенча муниципаль норматив хокукый актны, хокукый анализ, региональ законнарның АИС Кодекс - Аналитик системасы ярдәмендә хокукый җайга салу җитешсезлекләренә мониторинг ясау максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Исәнбай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау турында” Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының 22.01.2018 елның 36-2 номерлы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Сираев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге
Советының 2023 елның 10 февралендәге
30-2 номерлы карары белән расланды

“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Исәнбай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау турында” Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының 22.01.2018 елның 36-2 номерлы карарына кертелә торган үзгәрешләр

1. 11 өлешнең 11.1 пунктындагы 11.1.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;
2. 11 өлешнең 11.3 пунктындагы 11.3.3 һәм 11.3.4 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга.